**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының КамаТамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 елның 20 декабре** **143 номерлы**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтләр турында”гы 2016 елның 21 апрелендәге 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә.:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, теркәлүне раслый торган документ;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, Совет ур. (МСУ бинасы);

ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп, К.Маркс ур.105 йорт,(китапханә бинасы) ;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз остемә алам.

"Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы"
муниципаль берәмлек башлыгы, Совет рәисе В.П. Сороковнин